СОРАУ–ҖАВАП
Сихер нәрсә ул?
→ 4–5 БИТЛӘР

ВӘГАЗЬ
Раҗәб аеның фазыйләтләре
→ 6 БИТ

МИРАС
Без – вакфлар мәдәнияте
→ 10–11 БИТЛӘР

СӘЛАМӘТЛЕК
Дәвалануның төп юллары
→ 14 БИТ



**ДЕКАБРЬ, 2024**
№ 12 (353)


Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы

ҖӨМӘДӘЛ-ӘҮВӘЛ – ҖӨМӘДӘЛ-АХЫР, 1446


# دين و معيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+


Фотоның авторы: Mansour / unsplash.com

## 2025 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр җәдвәле

8 НЧЕ БИТТӘ

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!

# Мәчкәрә авылының тарихи мәчете манарасына ярымай куелды


Фотоның авторы: Илнур Мифтахов/dumrt.ru

**Җөмәдәл-ахыр аеның 11 нче көнендә (12 нче декабрь) Кукмара районының Мәчкәрә авылындагы тарихи Җәмигъ мәчетендә торгызылган манарага ярымай кую тантанасы булып узды. Әлеге мәчет 1791–1793 елларда сәүдәгәр Габдулла Үтәмешев тарафыннан төзелгән һәм төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты булып тора. Ул Кукмара районы, Мәчкәрә авылы, Үзәк урам, 36 нчы йорт адресы буенча урнашкан.**

Әлеге мәчет татар архитектурасына хас үзенчәлекле мирас булып тора, ул үзенең тарихи кыйммәтен бүгенге көнгә кадәр саклап кала алган. 1920 елларда мәчет ябыла, аннары манарасы сүтелә, ә бина үзе авыл хуҗалыгы максатларында файдаланыла. 2022 елда мәчетне төзекләндерү эшләре башланды.

Мәчет үзенчәлекле бай бизәкләре, гөмбәзләре белән таң калдыра, алар безнең көннәргә кадәр беренчел кыяфәтендә сакланып калган. Бина таушалмасын өчен, иң беренче чиратта башкарылган эшләр кысаларында фундаментларны ныгыту, таш дивардагы ярыкларны төзәтү эшләре тәгәлләнгән, бинага су зыян салмасын өчен эшләр башкарылган.

**dumrt.ru сайтыннан алынды**

# Гомрәгә — бөтен авыл белән: Татарстан тарихында беренче тапкыр кече хаҗга бер авылдан берьюлы 26 кеше китте

**20 декабрьдә төнлә Казанга изге җирләрдән – Мәккә һәм Мәдинәдән – үзенчәлекле хаҗилар төркеме кайтып төште: республика тарихында беренче тапкыр гомрә хаҗына бер авылдан берьюлы 26 кеше барды. Төркем тулысынча Балык Бистәсе районының Балтач авылында яшәүчеләрдән тора. Алар белән бергә авылдашларының мөһим сәфәргә чыгуына сәбәпче булган авыл имамы Фердинанд хәзрәт Хәкимов та китте. Сәфәр чыгар алдыннан авыл кешеләре юлдашларын озатып калды, хәтта, хәлләреннән килгәнчә, акчалата ярдәм дә итте.**


Фотоның авторы: Илнур Мифтахов/dumrt.ru

Әлеге төркем гомрәгә Балык Бистәсе районы имам-мөхтәсибе Рамазан хәзрәт Хисаметдинов җитәкчелегендә барды. Йолаларны үтәү хәнәфи мәзһәбенә нигезләнеп оештырылды. Мәдинәдә балтачлылар Мөхәммәд Пәйгамбәр галәйһиссәлам мәчете янындагы кунакханәдә тукталды. Ә Мәккәдә Әл-Хәрам мәчетеннән ерак булмаган дүрт йолдызлы кунакханәдә яшәде.

Гомрә йолаларын үтәүдән тыш, алар истәлекле урыннарда: Куба һәм Ике Кыйбла мәчетләрендә, Өхед тавында, хөрмә бакчасында, Әл-Бакыйг зиратында, Нур тавында, Хира мәгарәсендә, шулай ук хаҗ кылу урыннарында, мәсәлән, Гарәфәттә, җәмәратта (таш ату урыны), Мина һәм Мөздәлифәдә булды.

**dumrt.ru сайтыннан алынды**

# Татарстан мөфтиятенең «Хәләл» стандарты комитеты Фарсы култыгы илләрендә аккредитация алды

**Җөмәдәл-ахыр аеның 10 нчы көнендә (11 нче декабрь) Казанда «Татарстан Республикасында товар җитештерүчеләр арасында хәләл стандартларын кертү. Хәзерге торышы һәм перспективалар» дип аталган түгәрәк өстәл, шулай ук җитештерүгә хәләл стандартын кертү буенча практик семинар узды.**



Фотоның авторы: Илнур Мифтахов / dumrt.ru

Әлеге чаралар Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы ярдәмендә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча комитеты тарафыннан оештырылды. Түгәрәк өстәлдә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы вәкилләре, шулай ук Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы, муниципаль берәмлекләрнең башкарма органнары, җәмәгать туклануы предприятиеләре, эшкәртү предприятиеләре вәкилләре һәм экспертлар катнашты.

Түгәрәк өстәлдә хәләл стандарты буенча азык-төлек җитештерү өлкәсендә бизнес өчен карарлар эшләү; Татарстан муниципаль берәмлекләрендә хәләл стандартларны кертүгә йогынты ясый торган факторлар; хәләл индустрия проблемаларының фәнни нигезләре һәм хәләл азык-төлек экспортерларына ярдәм чаралары турында фикер алыштылар.

Очрашуда ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты рәисе Габбас хәзрәт Шляпошников мөһим белдерү ясады: 2024 елның ноябрендә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Хәләл стандарты комитеты Фарсы култыгы илләрендә, шул исәптән Согуд Гарәбстанында, Күвәйт, Бәхрәйн, Катар, Оман һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә аккредитация алды. Хәзер гомуми аккредитациядән соң бу илләрнең һәрберсендә өстәмә раслау узарга кирәк, бу нотификацияләү процессы дип атала.

– Без инде берничә дәүләттә нотификацияләү процессын уңышлы уздык һәм бу эшне Гарәп Әмирлекләрендә һәм Согуд Гарәбстанында актив дәвам итәбез, – дип хәбәр итте Габбас хәзрәт. – Безнең максат – Татарстан һәм башка җитештерүчеләрнең продукциясен Фарсы култыгы илләренә экспортлау мөмкинлеген тәэмин итү, моның өчен чит ил вәкилләрен чакыру яки халыкара аудиторлар чакыруның кирәге калмас. Без сертификацияләү буенча барлык мәсьәләләрне хәл итәргә омтылабыз. Аккредитация Фарсы култыгы илләре стандартларына гына түгел, SMIIC таләпләренә дә (Төркиядә Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы каршындагы Стандартлаштыру һәм метрология институты стандартлары) туры килүне раслау процессын җиңеләйтәчәк.

Түгәрәк өстәлдә видеоконференцэлемтә буенча SMIIC генераль сәркатибе (Ислам хезмәттәшлеге оешмасы каршындагы стандартлаштыру һәм метрология институты, Төркия) Ихсан Овут үзе дә чыгыш ясады, ул үз оешмасының эшчәнлеге турында сөйләде: «Без, материалистик максатлар белән бирелә торган логотиплар һәм сертификатлар кысаларыннан чыгып, хәләлгә бербөтен якын килү ягында торабыз. Әмма без консенсус, фәнни методологияләр һәм махсуслаштырылган экспертизага нигезләнгән стандартларның кирәклеген ассызыклыйбыз. Моңа бәйле рәвештә, Татарстанда җитештерүчеләр арасында ИХО/SMIIC Halal стандартларын кертү берничә сәбәп аркасында хәлиткеч әһәмияткә ия. Әлеге бердәм стандартларны кабул итү барлык хәләл продуктларның бертөрлелеген, ышанычлылыгын һәм сыйфатын тәэмин итә, бу эчке һәм халыкара дәрәҗәдә кулланучыларның ышанычын саклап калу өчен бик мөһим», – диде ул.

Шулай ук SMIIC генераль сәркатибе Ихсан Овут сүзләренчә, Ислам хезмәттәшлеге оешмасының SMIIC стандартларына туры килү Татарстанда җитештерүчеләргә яңа базарларга чыгу һәм экспорт мөмкинлекләрен киңәйтеп, Россиядәге хәләл продуктларга булган дөньякүләм ихтыяҗны уңышлы канәгатьләндерергә мөмкинлек бирәчәк. Мондый алым Татарстанда хәләл индустриянең икътисади потенциалын үстереп кенә калмый, ә хәләл продукция белән тәэмин итүнең глобаль чылбырында хезмәттәшлек һәм ышанычка этәреп, төбәкнең халыкара стандартларны үтәргә әзерлеген дә ассызыклый.

2024 елның якынча нәтиҗәләре буенча, Татарстан 13 миллион долларлык хәләл продукцияне экспортка чыгарган. Бу хакта Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Рөстәм Гайнуллов хәбәр итте. Ул шулай ук Малайзия һәм Индонезия кебек илләр, шулай ук Фарсы култыгы, якын Көнчыгыш, Төньяк Африка һәм Көньяк-көнчыгыш Азия илләренең Татарстанның хәләл продукциясен кертү өчен өметле юнәлешләр булып торуын өстәде. Татарстан продукциясен сатып алучы илләрдә хәләл кондитер әйберләре, сөт һәм ит продукциясе аеруча зур кызыксыну уятуын әйте.

Чарада катнашучылар республикада хәләл индустриясен үстерү мәсьәләләрен ведомствоара һәм тармакара дәрәҗәдә хәл итәргә кирәклекне билгеләп үтте. Шулай ук икътисадның барлык секторларының тотрыклы эшләвенә ярдәм итә торган карарлар кабул итү өчен барлык кызыксынган якларның көчен берләштерү дә зарур.

**dumrt.ru сайтыннан алынды**


Фотоның авторы: Joanna Kosinska / unsplash.com

**? Сихер (бозым) нәрсә ул? Коръәндә бу хакта әйтелгәнме?**

Аллаһы Тәгалә безгә сихер турында Коръәндә дә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләре аша да мәгълүмат җиткерә. Беләбез, сихер белән пәйгамбәрләр дә очрашкан. Мәсәлән, Муса галәйһиссәлам вакытында сихерчелек бик көчле булган. Бу хакта Коръәндә әйтелә. Мәсәлән, Раббыбыз «Та. Һа» сүрәсендә болай дип әйтә: «Сихерче исә кая барса да, уңышка ирешмәс». Шулай ук Аллаһы Тәгалә сихерчелекнең көфердән булуын әйтә.

Нәрсә ул сихер? Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәне ничек бар, шулай яраткан. Ә сихер – ул менә шушы Аллаһы Тәгалә яраткан әйберләрне бозу, үзгәртү. Гади генә әйткәндә, сихер гадәти әйберне үзгәртү дигәнне аңлата. Сихерчелек динебездә тыелган. Бу көферлек, ширек (Аллаһы Тәгаләгә тиңдәшлек кылу) белән бәйле.

Бүген сихерчелек бик таралган. Имам буларак та моны күреп торам, кешеләр килеп, үзләре белән булган хәлләрне сөйлиләр. Мәсәлән: «Фәлән кеше белән күрешкән идем, кинәт хәлем бик начараеп китте, ул миңа бозым ясады бугай», – диләр.

Сихер ул, әлбәттә, кешеләр белән бәйле. Әмма иң әүвәл сихернең башы – җеннәрдән. Сихерчеләр, күрәзәчеләр җеннәр белән эшли. Динебез сихерчеләргә йөрүне катгый тыя.

**? Бозымның төрле билгеләре турында ишеткәнем бар. Кеше аңа сихер, бозым ясаганнарын ничек белә ала?**

Иң әүвәл шуны әйтәсем килә: кеше башы авырткан саен моны сихердән күрергә тиеш түгел. Авырыйбыз икән, башта тикшеренергә, табибларга барырга кирәк.

Әмма табибларга мөрәҗәгать итеп, алар инде авыруның бер сәбәбен дә билгели алмаса, шундый очракта бозым, күз тию турында сөйли алабыз.

Сихернең билгеләре мондый булырга мөмкин: кешенең һәрвакыт йокысы килә, берни эшлисе килми, әйтерсең лә ул депрессия халәтендә, ул фикерләрен туплый алмый, төрле-төрле начар уйлар килә башлый.

Балаларга күз тисә, гадәттә алар йоклый алмый, төнлә кычкырып-саташып уянып китә. Гаиләгә бозым ясалса, ир белән хатынның аралары бозылырга мөмкин. Шулай ук гаилә таркалу, ир белән хатынның арасы бозылу – шайтанның иң яраткан эшләренең берсе.

**? Намаз уку сихер яки күз тию зарарыннан коткара аламы?**

ИншәАллаһ, коткара ала. Беренчедән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакыт үзе тәһарәтле булып йөрде һәм өммәтенә дә тәһарәтле булып йөрергә тырышырга кушты. Ягъни бу инде адәм баласын күп мәшәкатьләрдән коткара.

Икенчедән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә өйгә кергәндә яки чыкканда, бәдрәфкә кергәндә укырга кирәк булган һ. б. шундый догаларны өйрәтеп калдырган һәм һәрвакыт эшне «бисмилләһ» белән башларга кушкан. Болар барысы да безне төрле зарардан, сихердән саклый.

Намаз да шулай ук – адәм баласы гыйбадәт кыла бит. Аллаһы Тәгалә: «Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым», – ди бит. Димәк, адәм баласының табигате ул, гыйбадәттә булу. Ул шушы гыйбадәтен үти икән, Аллаһы Тәгаләгә якын икән, Раббыбыз аны Үзе саклый. Шулай булгач, намаз да, тәһарәтле булу да, зикер кылу да – барысы да кешене сихер зарарыннан саклый ала.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай ук: «Олы һәм кече гөнаһлардан сакланыгыз», – дип әйтеп калдырган. Бу да адәм баласын сихерләрдән саклый. Чөнки, кеше бер гөнаһ кылып, тәүбә итмәсә, ул нишли? Аның рухи халәте зәгыйфьләнә. Ә шушы зәгыйфьлектән җеннәр-шайтаннар файдалана ала: вәсвәсә кыла, зуррак гөнаһларга китерә ала.

**? Кеше рәнҗеше төшү бозымнан аерыламы? Бу башка нәрсәме?**

Кеше рәнҗеше төшүне без бәддога дип тә атый алабыз. Бу бозымнан, сихердән аерыла.

Төрле хәдисләрдә безгә кайсы кешеләрнең догасы кабул булуы хәбәр ителә. Шулар арасында бер хәдистә мазлум бар. Ягъни бу җәберләнгән, золым (начарлык) күргән кеше. Мазлумның догасы кабул була. Менә шушы золым күргән кеше, хәтта үзе дә абайламыйча, рәнҗеткән кешесенә «сиңа да шул булсын» дип әйтергә, теләргә мөмкин, мәсәлән. Менә бу бәддога була. Башка гади генә мисал: машинада барганда, кемдер безне кистерә, кинәт кенә безнең каршыга килеп чыга да, без «машинаң ватылсын!» дип әйтеп куябыз, ди. Бу да бәддога була. Кеше моны гадәттә аңлап бетермичә әйтә.

Димәк, без чыннан да кемнедер рәнҗетеп, ул безгә каршы дога кыла икән, Аллаһы Тәгалә бу доганы кабул итәм дигән.

Монда шуны да әйтергә кирәк: мазлумның догасы кабул була икән, без бу форсаттан файдаланып, хәерле догалар кылырга тиешбез. Әгәр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышына карасак, күрәбез, ул беркайчан да начар дога кылмаган. Ә нинди авырлыклар, җәбер-золым күргән ул. Шулай ук, мәсәлән, Коръәннән без Фиргавен хатыны Асия радыяллаһу ганһәнең тарихын беләбез. Ул золым күргәч,

бәддога кылмады, ә үзенә иминлек сорады, догасы кабул булды. Һәр әйткән сүзебезгә карата игътибарлы булсак иде, аларның һәрберсе язылып бара бит.

Димәк, сихер, күз тию, кеше рәнҗеше төшү – болар өчесе өч төрле күренеш. Иң хәтәре, куркынычы – сихер. Ул динебездә тыелган. Ә күз тидерү, бәддога кебек нәрсәләрне кешеләр белмичә, абайламыйча да кылырга мөмкин.

Бигрәк тә әти-әниләребез, туганнарыбызның хакын бозудан, рәнҗетүдән сакланырга кирәк.

**? Сихер-бозымны бары тик догалар белән генә дәвалап буламы?**

Аллаһы Тәгаләгә инанган кеше, әлбәттә, беренче чиратта, Раббысыннан ярдәм сорый. Һичшиксез, ихлас дога ярдәм итә ала.

Монда бер хәдисне искә аласым килә. Бер тузанга батып, талчыгып беткән кеше бара һәм дога кыла, Раббысыннан сорый икән. Әмма Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм санап китә: аның ризыгы да харам, кигән киеме дә харам, ди. Ничек Аллаһы Тәгалә бу кешегә җавап бирергә тиеш? Дога кылуның да тәртибе бар. Кеше гөнаһларын калдырмый икән, тәүбә кылмый икән, мәсәлән, ул аракысын да эчә, зина да кылып йөри икән, һәм шул ук вакытта сихердән ярдәм сорап, Аллаһы Тәгаләгә дога кыла. Ул аңа ярдәм итәрме? Доганың ярдәм итүен телибез икән, күңелебез, гамәлләребез чиста булсын, ризыгыбыз, кигән киемнәребез хәләл кәсеп белән килгән булсын. Шул вакытта Раббыбыз догаларыбызга җавап бирә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам – һәрбер кеше өчен иң яхшы үрнәк. Бу дөньяда сихер-бозымнан, күз тиюләрдән, шайтаннардан сакланасыбыз килә икән, безнең халәтебез камил булырга, рухи халәтебез нык булырга тиеш. Күңеле белән дә, тәне белән дә зәгыйфь булган кешегә төрле золым тәэсир итә ала.

*«Хозур» телеканалындагы «Имамнан сорыйк» тапшыруыннан. Сорауларга «Әл-Мәрҗани» мәчетенең имамы Айморат хәзрәт Хаҗиев җавап бирде.*

**Тапшыруга сорауларыгызны huzurtv@huzur.ru электрон почтасына җибәрә аласыз.**

# ҮЛЕМ ТҮШӘГЕНДӘГЕ КЕШЕ ЯНЫНДА ҮЗЕҢНЕ НИЧЕК ТОТАРГА?

**Мохтазар – үлем алды газабын кичерүче кеше. Үлем түшәгендә яткан кешене соңгы мизгелләрендә генә, тормышның ахыры ап-ачык булып күренеп торганда гына мохтазарга саный алалар.**

Үлем билгеләренә түбәндәгеләр керә:

– кешенең аяклары суына, хәлсезләнә;

– сулышы авырая, тизләшә, өзек-өзек була башлый;

– борыны җиңелчә бөгелә.

Мохтазар янында булучылар аңа рухи яктан ярдәм итәргә тиешләр.

**1. Үлем хәлендәге кешенең янында госелле булу хәерле.** Мохтазарның колагына акрын тавыш белән тәлкыйн кылалар: тәһлил яисә шәһадәт сүзләре әйтелә, үзенә көчләп әйттерергә ярамый.

Тәһлил: «Ләә иләһә илләллаһ».

Шәһадәт кәлимәсе: «Әшһәдү әл ләә иләәһә илләллааһу вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһүү вә расүүлүһ».

Бу сүзләрне әйтүнең максаты – боларны үлем хәлендәге кешенең исенә төшерүдер.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бер хәдисендә: «Соңгы сүзе «Ләә иләһә илләллаһ» булган кеше җәннәткә керер», – дип әйтә.

**2. Аның янындагылар Коръәннең 36 нчы «Йәсин» яки 67 нче «Әл-Мүльк» («Тәбәрак») сүрәсен укырлар.** Динебез бу сүрәләрне укуны саваплы күрә. Үлем хәлендәге кеше янында «Йәсин» сүрәсен уку үлем газабын җиңеләйтә.

**3. Үлем хәлендәге кешенең янында Коръән укый белмәгәннәр туган телләрендә хәер-дога кылырлар.**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бер хастаның яисә бер мәетнең янында булсагыз, хәерле бер сүз әйтегез. Чөнки фәрештәләр ул сүзнең кабул ителүе өчен «Әмин» дип дога кылырлар», – дигән.

Якын иптәше Әбү Сәләмә радыяллаһу ганһе вафат булганда да, Пәйгамбәребез аның өчен хәер-дога кылган, кардәше өчен Аллаһыдан рәхмәт һәм мәгъфирәт сораган, ахирәттә зур дәрәҗәләр, каберендә рәхәтлек теләгән.

Мохтазарны «Ләә иләһә илләллаһ» кәлимәсен әйтергә мәҗбүр итү кирәкми. Кәлимә, мохтазар да аны кабатласын өчен, аның колагына ишетелергә тиеш. Мохтазар кәлимәне әйткәнче, янындагылар кәлимә әйтүне дәвам итәргә тиешләр. Мохтазар кәлимәне әйткәндә, аның янындагылар эндәшми торырга тиешләр. Мохтазарның һаман кәлимә әйтеп торуына басым ясарга кирәкми. Соңгы мизгелгә кадәр аны әйтеп тору мөһим түгел. Максат шунда ки – бу кәлимә үлем түшәгендә ятучының дөньяда әйтелгән соңгы сүзләре булырга тиеш.

Ә мохтазар кәлимәдән соң башка сүзләр сөйләсә, янындагылар, ул да кабатласын өчен, тагын кәлимә әйтә башларга тиешләр. Мохтазар яңадан кәлимәне әйткәннән соң, тынлык сакланырга тиеш.

Соңгы мизгелләр якынайганда, мохтазар авыр итеп, тиз-тиз сулаганда, янындагылар тагын, кычкырып, кәлимә әйтергә тиешләр. Мохтазар янында дөнья сүзләре сөйләшергә ярамый, чөнки ул мохтазарны дөньялыкка тарта. Бу темага сөйләшү зыянлы. Үлүче Аллаһы Тәгалә турында уйласын дип тырышырга кирәк. Дөньяга тартылучы йөрәк белән бакыйлыкка күчүнең ахыры начар була.

**«Мәет озату йолалары» китабыннан («Хозур» нәшрият йорты)**

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 12 (353) декабрь, 2024 | җөмәдәл-әүвәл–җөмәдәл-ахыр, 1446

# Раҗәб аеның фазыйләтләре

**Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы исеме белән башлыйм.**

Аллаһы Тәгалә вакытны бер дә туктап тормый, һәрвакыт хәрәкәттә булган берәмлек итеп яраткан. Менә тагын бер фазыйләтләргә бай ай – раҗәб ае ишек шакый. Шул айның өстенлекләрен искә төшереп узыйк. Һәрвакыт белем алып тору, белгәнне искә төшерү – мөселманның асыл сыйфатыдыр.

Билгеле ки, раҗәб, шәгъбан һәм Рамазан изге айлардан санала. Алдагы икесе Рамазан аена әзерлек, үз-үзеңне рухи һәм физик яктан чыныгуга, чистарынуга, үзгәрүгә әзерлек вакыты булып тора. Раҗәб ае җиттеме, димәк, изге Рамазан аена тагын бер адымга якынлаштык дигән сүз.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Коръән сүзе кеше сүзеннән өстен булган кебек, раҗәб ае башка айлардан аерылып тора. Шәгъбан аеның өстенлеге исә – минем башка илчеләрдән өстенрәк торуыма тиң. Ә Рамазан аеның өстенлеге – Аллаһының Үз мәхлукларыннан өстен булуы кебек үк».

Раҗәб ае – ярлыкау һәм мәрхәмәткә ирешү ае ул. Атамасы «әр-руҗүб» сүзеннән барлыкка килгән, бу сүз «бөекләү, олылау» мәгънәсенә ия.

Раҗәб ае – мөселман ай календареның җиденче ае, ул харам айлар рәтенә керә. Әбү Бәкрат радыяллаһу ганһедән риваять кылына: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Бер ел унике айдан гыйбарәт, шуларның дүртесе – харам айлары, ә аларның өчесе рәттән килә: зөлкагъдә, зөлхиҗҗә һәм мөхәррам, ә «раҗәб мүдарр» җөмәдәл-ахыр һәм шәгъбан арасында» (әл-Бохари, Мөслим).

Ни өчен хәдистә раҗәб ае «раҗәб мүдарр» дип аталган? Бу Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең шәҗәрәсендәге бер Мүдара атлы кеше белән бәйле. Шушы кешенең кавеме раҗәб аеның вакытын күчерми торган була, башка гарәп кавемнәре, сугышны туктатып тормас өчен, раҗәб аен кичектереп тора торган булалар.

Ислам тарихы сәхифәләрен барласак, раҗәб ае нинди вакыйгаларга бай икән соң? Беренчедән, иң зур вакыйгаларның берсе – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе хәзрәти Габдулла һәм әнисе хәзрәти Әминә бу айда никахлашып кавыша. Раҗәб аеның беренче җомгасы төнен зурлап «Рәгаиб кичәсе» дип йөртәләр. Бу төндә кылынган догалар кабул ителә, гөнаһлар кичерелә, иншәАллаһ.

Икенчедән, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдәге әл-Харам мәчетеннән әл-Кудс (Иерусалим) җирендәге әл-Әкъса мәчетенә күчеш ясый һәм Аллаһы хозурына күтәрелә. Бу вакыйга «әл-Исра вәл-Мигъраҗ» дип атала. Ул раҗәб аеның 27 нче төне дип исәпләнә.

Мигъраҗ вакыйгасы – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһы тарафыннан бүләк ителгән могҗизаларның берсе булып тора. Нәкъ менә Мигъраҗ вакытында галәмнәрнең Раббысы Үзенең колларына биш вакыт намазны фарыз итеп йөкли.

Шулай ук бер хәдистә болай диелә: «Мигъраҗ вакытында Аллаһының рәхмәте буларак өч нәрсә бүләк ителде: биш вакыт намаз, «әл-Бәкара» сүрәсенең соңгы аятьләре һәм күп илаһларга табынучы булмаганнарга гафу кылыну мөмкинлегенең барлыгы» (Мөслим).

Аллаһының Расүле үзенә кадәр җиргә хакыйкатьне җиткерүчеләр булып җибәрелгән Ибраһим, Муса, Гайсә, Идрис, Йосыф галәйһимуссәлам кебек пәйгамбәрләр белән күрешә. Мигъраҗ вакыйгасы Коръәндә болай дип сүрәтләнә:

> ***«Ул Раббысының иң бөек аятьләреннән иң әһәмиятле бер өлешен** [Мигъраҗ кичәсендә] **күрде».***
>
> *«Ән-Нәҗм / Йолдыз», 53:18*

Раҗәб аенда өстәмә уразалар тотарга ният кылсак, хәерле булыр. Билгеле ки, ураза тоту – Аллаһы һәм Аның колы арасында гына кала торган гыйбадәт төре. Нәкъ тә шуның өчен савабын да, Аллаһы Тәгалә күпме бирергә теләсә, шуның кадәр билгеләячәк.

Бер хәдисендә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Раҗәб аенда ураза тотыгыз, чөнки бу айдагы ураза тоту Аллаһы тарафыннан аерым бер тәүбә буларак кабул ителә», – дип әйткән. Әгәр дә тулы бер ай ураза тоту мөмкинлеге юк икән, мәсәлән, кешенең сәламәтлегенә зыян килә яисә эше буенча мәшәкатьләре туа икән, бу очракта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм айның беренче, унбишенче һәм соңгы көннәрендә ураза тотарга киңәш иткән. Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Исегездә тотыгыз: раҗәб – Аллаһы Тәгаләнең ае, бу айда берәрегез бер көн генә булса да ураза тотса, Аллаһы аннан разый булыр», – дип хәбәр иткән.

Шулай ук Әбү Давыдтан китерелә торган хәдистә болай дип әйтелгән: «… харам айларда ураза тот һәм авыз ач, харам айларда ураза тот һәм авыз ач, харам айларда ураза тот һәм авыз ач…» Күргәнегезчә, Аллаһының Расүле бер үк гыйбарәне өч тапкыр рәттән кабатлый. Бу – әлеге айларда ураза тотуның никадәр әһәмиятле һәм саваплы булуына ныклы дәлил, мөселман өммәтенә катгый киңәш.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әлхәмдүлилләһ, без янәдән, инде менә гомеребездә ничәнче кат Рамазан аена якынлашабыз. ИншәАллаһ, без исән-имин аңа бер халәттә кереп, икенче халәттә чыгарбыз. Хәзер исә без юлыбызның беренче баскычында – раҗәб аенда – басып торабыз. Рамазан аен күңелебезгә бөтен фазыйләтләре белән кунакка кертергә телибез икән, бүгеннән үк әзерлек эшләрен алып барыйк: ураза тотыйк; бәхәсләрдән, вак-төяк ызгыш-талашлардан, низаглардан тыелып торыйк; күңелебезне Изге Коръән сүрәләрен уку белән бизик, гөнаһлардан тыелыйк һәм игелекле гамәлләрне тагын да арттырыйк.

**Ирек хәзрәт Нуриев,
Менделеев районы
имам-мөхтәсибе**

# Әбү әд-Дәрдә радыяллаһу ганһе

**Әбү әд-Дәрдә радыяллаһу ганһе – мәшһүр сәхабә, Коръән, хәдисләр, фикһ белгече, казый. Аның үз исеме Говәймир бине Зәйд була. Дәрдә исемле кызы булганга күрә, аны – Әбү әд-Дәрдә дип, ә Мәдинә шәһәрендә туып, әнсарлардан булганга, әл-Әнсарий дип атаганнар.**

## ХӘЗРӘТИ ӘБҮ ӘД-ДӘРДӘНЕҢ ГЫЙЛЕМ ДӘРӘҖӘСЕ

Хәзрәти Әбү әд-Дәрдә радыяллаһу ганһе Ислам динен Бәдер елында кабул итә. Бу вакытка кадәр ул сәүдә белән шөгыльләнгән була, ә дингә килгәч, үзен тулысынча гыйбадәткә һәм гыйлем алуга багышларга була, сәүдәсен калдыра.

Ул Коръәни Кәримне өйрәнүдә зур тырышлык куя. Хәзрәти Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе болай дип әйткән була: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үлгәндә Коръәнне җыйган кешеләр дүртәү иде: Әбү әд-Дәрдә, Мөгаз бине Җәбәл, Зәйд бине Сәбит, Әбү Зәйд». Ягъни, галимнәребез аңлаткача, күп сәхабәләр Коръәнне ятлый башлаган булса да, бу вакытта аларның зур күпчелеге аерым сүрә яки аятьләрне белмәгән, ятларга өлгермәгән, ә нәкъ бу дүрт сәхабә Изге Коръәнне тулысынча ятлаган була, алар яттан белмәгән аятьләр калмый.

Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе Әбү әд-Дәрдә радыяллаһу ганһене Димәшкъ шәһәренә (Сүрия) кешеләргә Коръән өйрәтергә җибәрә. Галимнәр аны Коръән ятлау түгәрәкләрен оештырып җибәргән беренче кеше дип атый. Аның түгәрәкләрендә 1500 дән артык шәкерт булуы хәбәр ителә. Тарихка ул «Димәшкъның карые (яттан Коръән укучы)» исеме белән дә кереп кала.

Әбү әд-Дәрдә радыяллаһу ганһе күп вакытын Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында үткәрергә тырышкан, нәтиҗәдә ул 179 хәдис тапшырган, фикһ галиме булып ирешкән. Коръәнне, Ислам шәригатен бик яхшы белгәнгә, ул Димәшкъ шәһәренең казые итеп билгеләнгән.

Кешеләрнең сорауларына җавап бирү, вәгазь-нәсыйхәтләрен җиткерү өчен, ул кешеләрне мәчетләргә дә җыя, базарларга да йөри торган булган. Ягъни Ислам динен тарату өчен бар мөмкинлекләрдән файдаланган.



Фотоның авторы: Abd Alrahman Omer Kareem / ar.wikipedia.org

## ХӘЗРӘТИ ӘБҮ ӘД-ДӘРДӘНЕҢ НӘСЫЙХӘТЛӘРЕ

Берзаман хәзрәти Әбү әд-Дәрдә урамда бер төркем кешеләрнең бер кардәшләрен сүгеп, аны кыйный башлауларына тап була. Ул моның сәбәбен сорагач, кешеләр: «Ул фәлән зур гөнаһ кылды!» – дип җавап кайтара. Әбү әд-Дәрдә радыяллаһу ганһе: «Бу кардәшегез коега төшкән булса, сез аңа аннан чыгарга ярдәм итәр идегезме?» – дип сорый. «Әйе! Әлбәттә!» – ди төркем. Шуннан ул: «Аны сүкмәгез һәм кыйнамагыз, ә үгет-нәсыйхәт бирегез. Сезне дә шундый гөнаһка төшермәгәне өчен, Раббыгызга шөкер кылыгыз», – дип киңәш бирә. Кешеләр гаҗәпләнеп: «Әллә ул синдә нәфрәт тудырмыймы?!» – ди. Ә Әбү әд-Дәрдә: «Аның гөнаһы миндә нәфрәт тудыра. Ә әгәр ул бу гөнаһын калдырса, ул минем кардәшем булачак», – дип әйтә. Бу сүзләрдән соң гөнаһ кылучы елый-елый тәүбә кыла. Башкалар да хаталарын аңлый.

Димәшкъ шәһәренә Әбү әд-Дәрдә радыяллаһу ганһе янына Мәдинәдән бер мөселман килә. Бу кеше йөзләгән чакрымнар уза. Хәзрәти Әбү әд-Дәрдә аннан: «Син нинди максат белән килдең?» – дип сорый. Мосафир: «Мин бер хәдисне өйрәнергә дип килдем. Синең Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисен сөйләвең турында ишетеп килдем мин», – ди. Әбү әд-Дәрдә: «Син сәүдә эшләре белән дә килмәдеңме? Син үзеңнең йомышың буенча да килмәдеңме?» – дип сорый. Бу кеше юк дип җавап кайтара. Шуннан соң сәхабә мондый хәдисне китерә: «Мин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәнен ишеттем: «Гыйлем алу нияте белән юлга чыккан кешегә Аллаһы Тәгалә җәннәткә юлны җиңеләйтер. Фәрештәләр, аннан разый булган хәлдә, аның алдында канатларын җәярләр. Дөреслектә, галим өчен күктәге һәм җирдәге бар мәхлуклар гафу үтенә, хәтта судагы балыклар да. Һәм галимнең башка гыйбадәт кылучылардан фазылы (өстенлеге) тулган айның башка күк җисемнәреннән өстенлегенә тиң. Һәм, дөреслектә, галимнәр – пәйгамбәрләрнең варисларыдыр. Ә пәйгамбәрләр мирас итеп динарлар да, дирһәмнәр дә калдырмыйлар, ә гыйлем калдыралар. Һәм моны алучы зур өлеш алыр» (имам Әбү Давыд, әт-Тирмизи һ. б. китерә).

Хәзрәти Әбү әд-Дәрдә радыяллаһу ганһе бик дәрәҗәле кеше булуына карамастан, бик тыйнак булган, дөнья малыннан ваз кичкән. Ул болай дигән: «Әгәр шушы өч әйбер комачауламаса, кешеләр тәкъва булырлар иде: алар ияргән нәфесләре, алар буйсынган саранлыклары һәм үз фикерләре белән сокланулары».

Шулай ук Димәшкъ халкына ул болай дип мөрәҗәгать иткән булган: «Дөреслектә, сез үзегез файдаланмаячак нәрсәләрне туплыйсыз, үзегез күрмәячәк нәрсәләргә өметләнәсез, үзегез яшәмәячәк нәрсәләрне төзисез. Сезгә кадәр яшәүчеләр күп мал туплаган, зур өметләр белән яшәгән, биек биналар төзегән. Әмма аларның малы юкка чыккан, өметләре алдану булган, ә йортлары булып каберләре тора. Гад кавеме Гаден шәһәре (Йәмән) белән Гамман (Иордания) арасындагы җирне ат һәм дөяләре белән тутырган. Әмма кайсыгыз хәзер миннән Гаднең мирасын ике дирһәмгә булса да сатып алыр?»

**Сәхифәне Әминә Гыйззәт әзерләде**

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 12 (353) декабрь, 2024 | җөмәдәл-әүвәл–җөмәдәл-ахыр, 1446

# 2025 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр

## һиҗри 1446–1447 еллар

| Милади | һиҗри | |
|---|---|---|
| 1 гыйнвар | 1 раҗәб | |
| 2 гыйнвардан 3 сенә каршы төн | 2 раҗәб | **Рәгаиб кичәсе** |
| 26 гыйнвардан 27 сенә каршы төн | 26 раҗәб | **Мигъраҗ кичәсе** |
| 31 гыйнвар | 1 шәгъбан | |
| 13 февральдән 14 енә каршы төн | 14 шәгъбан | **Бәраәт кичәсе** |
| 1 март | 1 Рамазан | **изге Рамазан ае башлана** |
| 26 марттан 27 сенә каршы төн | 27 Рамазан | **Кадер киче** |
| 30 март | 1 шәүвәл | **Ураза гаете** |
| 29 апрель | 1 зөлкагъдә | |
| 28 май | 1 зөлхиҗҗә | |
| 5 июнь | 9 зөлхиҗҗә | **Гарәфә көне** |
| 6 июнь | 10 зөлхиҗҗә | **Корбан гаете** |
| 5–9 июнь | 9, 10, 11, 12, 13 зөлхиҗҗә | **тәкбир әт-тәшрикъ көннәре** |
| 26 июнь | 1 мөхәррам | **һиҗри 1447 ел башлана** |
| 5 июль | 10 мөхәррам | **Гашурә көне** |
| 26 июль | 1 сафәр | |
| 24 август | 1 рабигыль-әүвәл | |
| 3 сентябрьдән 4 енә каршы төн | 12 рабигыль-әүвәл | **Мәүлид ән-Нәби** |
| 23 сентябрь | 1 рабигыль-ахыр | |
| 23 октябрь | 1 җөмәдәл-әүвәл | |
| 21 ноябрь | 1 җөмәдәл-ахыр | |
| 21 декабрь | 1 раҗәб | |

# «Татарстан чит ил мөселман партнерларына бик күп кызыклы проектлар тәкъдим итәргә әзер»



Фото: rais.tatarstan.ru

**Җөмәдәл-ахыр аеның 10 нчы көнендә (11 декабрь) Куала-Лумпурда (Малайзия) «Россия–Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең күчмә утырышы узды. Утырыш «Формалашып килүче күппоярлык чорында Россия һәм ислам дөньясының үзара хезмәттәшлеге» дигән темага багышланды.**

Утырышта Азия, Африка һәм Якын Көнчыгышның 32 иленнән, шулай ук халыкара оешмалардан 200 дән артык хакимият органнары вәкилләре, сәясәт, дин һәм җәмәгать эшлеклеләре катнашты. Алар арасында «Россия–Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме Рәисе, ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов; Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм «Россия–Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме әгъзалары булган башка вәкилләр һәм чакырылган экспертлар булды.

Камил хәзрәт Сәмигуллин, утырышта чыгыш ясап, «Россия–Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең хөрмәтле партнерларын Исламны үстерү өлкәсендә Татарстан һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте белән хезмәттәшлеккә чакырды. Ул республиканың чит ил мөселман партнерлары һәм инвестицияләр белән эшли белүен һәм динне ныгыту өчен күп кенә кызыклы проектлар тәкъдим итәргә әзер икәнлеген билгеләп үтте. Камил хәзрәт Татарстан Республикасының Россиянең икътисади яктан иң уңышлы төбәкләренең берсе генә түгел, илебезнең Ислам үзәге булуын да ассызыклап үтте.

Камил хәзрәт республикада Ислам үсеше өлкәсендәге мөһим юнәлешләрне тасвирлап, Татарстанның Россиядә ислам финансларын үстерү өлкәсендә иң эре үзәк булуын билгеләп үтте.

Татарстан Мөфтие Коръән бастыру һәм Коръәнне өйрәнү буенча мөһим проектларга да җентекләп тукталды. «Чит илләрнең ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә әзерләнгән мосхафларны яңадан бастырып чыгарырга сораулары Татарстанда Коръән бастыру үсешенең югары дәрәҗәсе турында сөйли. Әйтик, төрле елларда хәзерге Казан Коръәне Төркиядә, Үзбәкстанда, Беларусьта яңадан басылып чыкты», – диде Камил хәзрәт. Ә кулъязма Коръән әзерләү проекты ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең иң әһәмиятле китап бастыру проекты булып тора.

Татарстан Мөфтие шулай ук нәшрият эшчәнлеге (ул гомуми тиражы 1 млн данә булган 350 дән артык исемдәге китапны үз эченә ала), шулай ук татар дин галимнәренең 2000 томнан артык борынгы хезмәтләре урнаштырылган «Даруль-кутуб» электрон китапханәсе турында җентекләп сөйләде. «Чит ил дин белгечләре аның белән бик кызыксына, чөнки биредә хәзинәгә тиң өйрәнелмәгән материаллар табалар. Әйтик, 2022 елда Бәхрәйн Корольлегенең Югары шәригать суды рәисе, доктор Ибраһим әл-Мүрайхинең күренекле татар дин галимнәре эшчәнлегенә багышланган «Казан галимнәренең иҗазәтләре» дигән өч томлык фәнни хезмәте басылып чыкты», – дип билгеләп үтте Камил хәзрәт.

Ул үз чыгышында шулай ук Татарстанда хәләл индустриясе, мәгърифәтчелек медиапроектлары, хәйриячелек кебек юнәлешләргә дә кагылып үтте. Мөфти 2023–2024 елларда Татарстан һәм бөтен Россия мөселманнарының Газзәдәге дин кардәшләребез өчен ярдәм җыюда катнашканлыгын ассызыклап үтте: инде ничә көннәр дәвамында чолганышта булган халыкка гомуми авырлыгы 60 тонна булган 3 гуманитар йөк җибәрелгән. Бу мәсьәләдә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенә Татарстан Рәисе Рөстәм Нургали улы һәм Россиянең гадәттән тыш хәлләр министрлыгы теләктәшлек күрсәткән – махсус очкычлар биргән.

«Россия–Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышында очрашуның төп бурычы формалашып килүче күпполяр дөньяда, үзара хезмәттәшлек параметрларын билгеләүгә басым ясап, даими үзгәреп торучы халыкара вәзгыять шартларында Россия Федерациясенең мөселман илләре белән мөнәсәбәтләре перспективалары турында фикер алышу булды.

Утырышта шулай ук 2024 елның маенда төркемнең Казан утырышында башланган гадел күпполярлы дөнья төзелешен һәм имин үсешне формалаштыруга кагылышлы мәсьәләләр, шулай ук сәяси, сәүдә-икътисади, мәдәни-гуманитар һәм рухи-әхлакый өлкәләрдә уртак эш перспективаларын тикшерү дәвам итте. Шулай ук икътисад, ислам банкингы һәм иминлек мәсьәләләрендә хезмәттәшлекне үстерүнең төп юнәлешләре турында сөйләшү булды.

«Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең бу утырышы Малайзия җитәкчелеге теләктәшлегендә узды. Россиянең ислам дөньясы белән мөнәсәбәтләре тарихында тагын бер әһәмиятле вакыйга нәкъ менә шушы ил белән бәйле: Президент В. В. Путин, 2003 елда Малайзиянең Путраджайя шәһәрендә Ислам конференциясе оешмасына кергән дәүләтләр һәм хөкүмәтләр башлыкларының X очрашуында чыгыш ясаганда, Россиянең Ислам Конференциясе Оешмасы эшчәнлегенә кушылу нияте барлыгы турында игълан итте. 2005 елда Россия мөселман илләре ярдәме белән бу халыкара структурада күзәтүче статусын алды.

**dumrt.ru сайтыннан**

# Без — вакфлар мәдәнияте



Фотоның авторы: Mauro Lima / unsplash.com

**Яхшылык эшләүнең нинди генә юллары юк. Бу дөньядагы һәр мизгел безнең өчен хәерле эшләр кылу мөмкинлеге булып тора. Аллаһы Тәгалә безне изге гамәлләр кылырга ашыгырга өнди:**

***«Сез*** *[кыйблага юнәлгән кебек, ике җиһан бәхете казандырырлык]* ***яхшы гамәлләргә ашыгыз».***

*«Әл-Бәкара / Сыер», 2:148*

Аллаһының әмеренә буйсынып, мөселман өммәте Пәйгамбәребез галәйһиссәлам һәм сәхабәләр вакытыннан ук вакфлар мәдәнияте булып торды. Мәсәлән, Пәйгамбәребезнең – җиде хөрмә бакчасын, җир кишәрлекләрен, ә хәзрәти Госман радыяллаһу ганһенең бик зур бәягә сатып алынган коеның бушлай мөселманнарга тапшыруын күпләребез беләдер. Сәхабәләр арасыннан вакф калдыручылар бихисап булган.

Мәшһүр галим Ибне Кудәмә: «Мин мөһаҗир һәм әнсарлар арасыннан җитәрлек малы булып, милекләрен вакф итеп калдырмаган бер генә кешене дә белмим», – дип язган.

### НӘРСӘ УЛ ВАКФ?

Вакф төшенчәсе телебездә бүгенге көндә бик таралган сүз булмаганга күрә, аның мәгънәсен ачыклап китик.

Вакф – ул нинди дә булса милекнең (кибетнең, җирнең, фатирның яки бинаның һ. б.) керемнәрен Аллаһы ризалыгы өчен бер яхшы эшкә багышлау.

Гарәп теленнән вакф сүзе «туктау» дип тәрҗемә ителә. Ни өчен туктау? Чөнки бер милекне, мәсәлән, бер бинаны вакфка әйләндергәч, аны киләчәктә сатарга да, васыять итәргә дә ярамый. Бу милекнең хуҗасы инде Аллаһы Тәгалә Үзе була.

Без беләбез, безгә бирелгән барлык мал, ризык, киемебез, йортларыбыз, машиналарыбыз – һәммәсе безгә вакытлыча гына бирелгән, аларның чын хуҗасы болай да Аллаһы Тәгалә. Әмма без машинабызны теләгән вакытта сата яки бүләк итә алабыз, теләсәк, икенче машинага алыштыра алабыз. Әмма без шушы күчемле яки күчемсез милкебезне вакфка әйләндерергә ниятләсәк, бу мал «туктап кала», әйләнештән (обороттан) чыга, шуңа ул вакф дип атала да.

Кыска һәм аңлаешлы мисал да китерик. Арабызда, әлхәмдүлилләһ, бай һәм урта хәлле мөселманнар күп. Без моңа сөенергә тиешбез, чөнки бай кешеләргә гыйбадәт кылырга өстәмә мөмкинлекләр ачыла: алар зәкят тә түли, хаҗга да акча бирә, вакф та кора ала.

Мисал өчен, бер эшмәкәр кардәшебезнең Казанда берничә офис һәм сәүдә үзәге бинасы бар. Ул бу биналарны арендага тапшыра, арендадан керем килеп тора. Әйтик, шушы биналарның берсе аена 10 миллион сум керем китерә, ди. Бөтен коммуналь түләүләр, бинаны тәртиптә тотуга киткән чыгымнар, эшчеләрнең хезмәт хакын һәм салымнарны түләгәннән соң, аена бу бинада 5 миллион табыш кала, дип санаек. Әйтик, 10 елга бер зур ремонт үткәреп алырга кирәк, моңа ай саен бер миллион сумны читкә куеп барыйк. Шулай итеп, ай саен шушы бинадан 4 миллион сум кала.

Бу мөселман кардәшебез шушы офис бинасын вакф итәргә ниятли. Моның өчен ул бу вакфтан кергән 4 миллион сум ничек тотылырга тиешлеген теркәп, җентекләп бер документ (мөселман дәүләтләрендә вакфнамә яки вакфия дип атала) төзи. Әйтик, кәгазьдә ул шуларны күрсәтә ала: бинаның калган чиста табышының 1/4 – Коръәнне ятлаучы балаларга стипендия итеп түләнсен, 1/4 – фәлән мәчетнең хисабына, имамнарга хезмәт хакы һәм коммуналь чыгымнарны каплау өчен түләнсен, 1/4 – яман авырулары булган кешеләргә ярдәм итә торган фондка җибәрелсен, 1/4 – шушы вакф белән идарә иткән оешмага юнәлдерелсен.

Соңгы пунктны аңлатып китик. Әйтик, үзе исән чакта кардәшебез бу 4 миллионны үзе дә таратып бара ала. Үлеменнән соң да эше дәвам итсен дисә, ул инде вакф малы белән идарә итәчәк бер команда төзеп куярга тиеш, һәм юридик яктан да бу бинаның статусын дөрес итеп билгеләргә тиеш. Димәк, үзе үлгәннән соң бу бина белән идарә итәчәк кешеләргә, бухгалтер һәм юристларга да хезмәт хакы түләнеп барсын өчен, болар да дөрес итеп теркәлгән булырга тиеш. Монда инде мөселман юристлар белән киңәшләшеп эш итәргә кирәк.

Шушы эшне башкарып чыкса, бу кардәшебез бакыйлыкка күчкәч тә корган вакфының әҗер-савабын алуын дәвам итәчәк. Чынлыкта бу бик зур нигъмәт, Аллаһының бер рәхмәте. Кешенең гомере чикле, ул бу дөньяда 60–80, күп булса 100 ел яши һәм фани дөньяның мал-ризыгын куллана ала. Әмма вакф итеп калдырылган мал кешегә Кыямәт көненә кадәр хезмәт итә ала, ә бу йөзләгән еллар булырга мөмкин.

### ВАКФЛАРНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

Ислам мәдәниятен аерып торган 3 сыйфат булып һәрвакыт әдәп, батырлык һәм мәрхәмәтлелек сыйфатлары торды. Мөселман мәдәнияте – мәрхәмәтлелек, кешеләр арасында җылылык, кардәшлек, «вакфлар

мәдәнияте». Һәм бу сүзләр тулысынча өммәтебезнең тарихы белән дәлилләнә.

Мөселман дәүләтләре тарихында да, безнең татар халкының тарихында да вакфлар әһәмиятле урын алып тора.

Бүгенге көндә дә дөньяда дистәләрчә мең вакфлар эшләп килә. Бу вакфларны коручылар инде күптән кабердә булсалар да, аларга шушы эшләренең савабы язылып тора.

Мәсәлән, хаждa яки гомрәдә булган кардәшләребезнең игътибар иткәне бардыр: Мәккә һәм Мәдинә урамнарында хаҗиларга бушлай су таратып торучылар була. Бу су өчен кем түли? Еш кына бу саваплы эш төрле вакфлар тарафыннан финанслана. Уйлап кына карагыз: бер мөселман 2024 елда хаждa су эчә, ә бу суны өләшеп торучы егетнең хезмәт хакы һәм су шешәсенең бәясе кайчандыр 500–600 ел элек яшәгән кеше калдырган хөрмә бакчасының керемнәреннән каплана!

Татарлар тарихына килсәк, Казан ханлыгында, әлбәттә, вакфлар булган. Ә Казан губернасында беренче рәсми рәвештә теркәлгән вакф булып 1830 елда язылган сәүдәгәр Гобәйдулла Юнысовның васыяте тора. Ул васыятендә Печән базарындагы ике таш кибетен Беренче Җәмигъ мәчетенә («әл-Мәрҗани» мәчете) тапшырган.

Инкыйлабка кадәр Казанның һәр мәчете вакфлар китергән акча хисабына яшәгән. Бу вакфлар булып биналар, сәүдә йортлары, кибетләр, җир кишәрлекләре торган. Шулардан килгән акчага мәчетләрнең бар чыгымнары капланган, мәдрәсәләребез үсеш алган.

Казанда гына түгел, белеп торабыз, Казан артында бик зур мәчетләр, мәдрәсәләр бар. Мәчкәрә, Кышкар, Иж-Бубый кебек мәдрәсәләр, кечкенә авылларда салынган булсалар да, үз керемнәре булганга күрә, үзләрен үзләре тәэмин иткән, мәдрәсәләребездә бик көчле мөгаллимнәр укыткан. Гомумән, татар байлары кайсы җирлеккә, илләргә бармасын, шунда мәчет-мәдрәсә төзеп, аларны тәэмин итәргә вакф та булдырырга тырышкан.

Бүген бу гыйбадәтханәләребезне торгызу, тәэмин итү җаваплылыгы безнең өстә, без моны зур савап эшләү мөмкинлеге буларак кабул итик. Мәчет-мәдрәсәләребез яхшы финансланса, имамнарыбыз ай саен мәчетнең газ-су чыгымнарын ничек капларга дип баш ватмаса, ә күбрәк балаларны укыту белән шөгыльләнсә, эшмәкәрләребез, мәхәллә халкы исә артык малларын Аллаһы юлына багышласа, Аллаһы Тәгалә безгә бәрәкәтне арттырыр иде, балаларыбыз тәрбиялерәк булыр иде. Без шуңа омтылырга тиеш.

## ГАДӘТИ БУЛМАГАН ВАКФЛАР

Тарихчылар Госманлы хәлифәлеге җирләренең 1/3 өлеше вакф милеге булып торуы турында яза.

Безнең дин кардәшләребез вакфларны корган вакытта фәкать Аллаһының ризалыгына омтылганнар. Һәм бары тик мөселманнарны, бары тик үз милләттәшләрен генә уйламыйча, вакфларны корганда бөтен кешелек дөньясына һәм хәтта җәнлекләргә дә яхшылык кылырга омтылганнар.

Төркиянең Вакфлар мөдирлеге нәшер иткән «Тарихта кызыклы вакфлар» (Tarihte İlginç Vakıflar) дигән китапта 100 гә якын гадәти булмаган, үзенчәлекле вакфлар турында мәгълүмат китерелә. Китапта тасвирланган шушы кызыклы вакфларның кайберләрен санап, алар турында мәгълүмат биреп китик.

Әлеге вакфлар арасында табигатьне кайгыртуга юнәлдерелгән вакфлар аерым урын алып тора. 1889 елда Измирның Өдәмеш шәһәрчегендә Мүрселли хаҗи Ибраһим ага бине Габдулла исемле кардәшебез ләкләкләр өчен вакф кора. Өдәмеш шәһәренең Яңа Мәчете янында ләкләкләрне ашату, карау һәм кирәк булса дәвалау өчен «ел саен вакф малыннан 100 куруш акча бирелергә тиешлеген» билгеләп калдыра.

1778 елда Истанбул шәһәрендә хаҗи Мостафа улы хаҗи Мостафа вакфы теркәлә. Аны оештыручы хуҗасыз урамда калган хайваннарны ашатырга дип васыять калдыра.

1585 елда Али бине Хәмзә Эдирнә шәһәрендә Али Мәчете янында үзе ясаткан тротуарны чисталыкта тоту һәм Чукурбостандагы күлне чисталыкта тоту өчен вакф кора. Игътибар итсәк, бу кардәшебез тротуар төзүгә садака бирү белән генә чикләнеп калмыйча, аның киләчәген дә кайгырткан. Бу җәяүлеләр юлы киләчәктә дә төзек һәм чиста торсын өчен, Али әфәнде бу эшне алдан ук финанслап куйган.

Динебез чисталыкка аерым игътибар бирә. Шул нисбәттән чисталыкны кайгыртуга бәйле махсус вакфлар барлыкка килгән дә. Моңа тагын бер мисал булып диварлардагы язуларны җую вакфы тора. Ул 1470 елда Истанбулда корылган була. Вакф максаты итеп шәһәрдәге мәчет-мәдрәсәләр, уку йортлары һ. б. шундый биналарның диварларын чистартып, буяп тору билгеләнә.

Әлбәттә, мөселманнар яшәгән һәр җирдә ярдәмгә мохтаҗ булган кешеләрне, фәкыйрьләрне кайгыртуга зур игътибар бирелә. 1588 елда Дийарбакыр шәһәре башлыгы Хүсрәв Паша Ван күлендә ашыгыч ярдәм күрсәтү һәм батучыларны коткару өчен бер көймә булдыру өчен вакф кора.

Сивас шәһәрендә мескен-фәкыйрьләргә кайнар пиделар (көлчә кебек юка икмәк) тарату өчен вакф булган.

1774 елда Измир шәһәрендә Әхмәт ага бине Синан бине Хәсән вакфы булдырыла. Бу вакф шарты итеп ел саен 500 куруш акчаны тәкъва, гыйлемле кешене хаҗга җибәрүгә бүлү куела.

Амасия шәһәрендә 1496 елда бик тә үзенчәлекле вакф булдырыла. Бу – ир балаларны сөннәтләү вакфы. Аның шарты буенча, мәдрәсәдә укучы ятим һәм фәкыйрь малайлар, сөннәтләнмәгән булсалар, шушы вакф акчасыннан сөннәткә утыртылырга тиеш булган һәм «сөннәтләнләнгән балага тиешле гүзәл киемнәр бирелер».

Истанбул шәһәрендә исә бер вакф фәкыйрь булган яшь кызларга бирнә әзерләшергә ярдәм иткән.

Мондый вакфлар динебезнең, тарихыбызның матурлыгын күрсәтә, киләчәк буыннар өчен мәрхәмәтлелек, бердәмлек үрнәге булып тора.

* * *

Төрле статистикалар, сораштырулар күрсәткәнчә, Россиядә бүген яшьләрнең 65% үз эшен, үз бизнесын булдырырга тели. Соңгы елларда Казан кебек зур шәһәрләрдә генә түгел, Татарстанда да, дин кардәшләребез яшәгән башка төбәкләрдә дә уңышлы бизнеслары булган кардәшләребезнең саны арта бара, Аллаһы Тәгалә аларның бәрәкәтләрен арттырсын.

Шулай ук бүгенге көндә яңа, матур, заманча җиһазландырылган мәчет-мәдрәсәләребез ачылып тора. Элекке чорда яшәгән дин кардәшләребез кебек безгә дә гыйбадәтханәләребезне күркәм рәвештә тәэмин итеп торырга насыйп булсын. Без дә үзебездән соң шушындый вакфлар калдырырга дип максат куйсак, шушы юлда эшләсәк, Аллаһы Тәгалә моңа юллар ачар.

**Сәхифәне Рәмзилә Маннанова әзерләде**

# Кәгазь җитештерүдә мөселманнарның өлеше

**Мөселманнар кәгазьне җитештерү һәм таратуга бик зур өлеш керткәннәр. Үз вакытында бу дөньяда китаплар арту, фән үсешенә дә нык тәэсир иткән.**

751 елда мөселманнар әсирлеккә алынган Кытай осталарыннан кәгазь җитештерү серләрен белгән. Багдад, Димәшкъ кебек зур шәһәрләрдә махсус кәгазь «фабрикалары» булдырылган. Кытайлар уйлап тапкан ысул белән ясалган кәгазь бик кыйммәткә чыкканлыктан, мөселманнар аны җитештерү эшен җиңеләйтергә һәм камилләштерергә булган.

Бу хакта мәшһүр галимебез Шиһабетдин Мәрҗани болай дип язган: «Һиҗри 88 елда Хиҗазда яшәүче Йосыф бине Гомәр әл-Мәкки кәгазьне мамыктан җитештерү ысулын уйлап тапкан. Мәгъриптә Муса бине Насыр кәгазьне җитен һәм киндердән җитештергән. Кәгазьне әүвәл Кытайда җитештерсәләр дә, мөселманнар аны җитештерү ысулларын үстереп вә камилләштереп, кәгазьне һәр җиргә, шул исәптән Европада да, тараткан. Исламгача язу кәгазе буларак пергамент кулланылган. Ул исә, сирәк һәм кыйммәт булганлыктан, бик аз кешедә булган.

Мөселманнар җитештергән югары сыйфатлы кәгазь шундый булган ки, аңа караган кеше үзенең чагылышын күрә алган. Ул кәгазь төрле төсләрдә җитештерелеп, аңа төрле бизәкләр төшерелгән».

Чыннан да, Димәшкъ шәһәрендә эшләнгән кәгазь күпләп Европа илләренә сатылган, чөнки Сүрия осталары югары сыйфатлы арзан кәгазь җитештерергә өйрәнгән. Алар киндер үстереп, аның озын һәм нык сүсеннән яхшы кәгазь ясаган. Бүгенге көндә дә бу ысул экология өчен зарарсыз һәм арзан ысулларның берсе булып тора.

Киндердән тыш, мөселманнар кәгазьне башка чималдан, мәсәлән, җитеннән һәм мамык тукымалардан да ясап караган. Алар уйлап тапкан ысул буенча, вакланган тукыма кисәкләре озак вакыт суда җебетелеп, кайнатылган, соңыннан төелгән. Соңрак бу рәвешле кәгазьне күп еллар дәвамында башка илләрдә дә ясаганнар.

800 елларда Мисыр мөселманнары да кәгазь җитештерә башлый. Тарихчылар фаразынча, кәгазьгә язылган беренче Коръән нөсхәсе дә X гасырда нәкъ Мисырда барлыкка килгән.

Моннан әлеге җитештерү ысуллары Мароккога, Әндәлуска (Испания) таралган. Анда да дин кардәшләребез гасырлар дәвамында кәгазьнең сыйфатын яхшыртып, шул рәвешле динебезнең таралуына, фән үсешенә зур өлеш керткән.

Кәгазьнең арзан булуы китаплар артуына китергән, мөселман илләрендә төрле фәннәрне өйрәнүче галимнәр, шәкертләр дә кульязма китапларын булдыра алган. Нәтиҗәдә мөселманнарда хатт (каллиграфия) сәнгате үскән, каләмнәр һәм язу карасы җитештерү өлкәләре дә алга киткән.

Кәгазь җитештерүнең яңа ысуллары мөселман дәүләтләреннән Европага да күчкән.

### ТАТАРЛАРДА КӘГАЗЬ

Халкыбызның кәгазь белән кайчан танышуын төгәл әйтүе авыр. Кайбер галимнәр фикеренчә, төрки телләргә «кәгазь» сүзе кытай теленнән кергән, башка фикер буенча, ул гарәп теленнән алынган.

Тарих фәннәре докторы Г. М. Дәүләтшиннең мәкаләсеннән Идел буе Болгарында кәгазь кулланылганын күрә алабыз: «Язу өчен төп материал буларак кәгазь кулланылган, ул гарәп имлясе өчен уңайлырак. Кәгазьдә язылган китаплар да булган. Аларның тышкы күренеше бик зәвыклы булган. Биләр коллекцияләрендә тышлыклары металлдан ясалып, матур дулкынлы бизәк, инкрустация белән бизәлгән шундый китаплар билгеле. Алар белем белән тулы тылсымлы тартмачыкларга охшаган. Гыйлем алганнан соң, китапны махсус кечкенә ыргаклар белән ябып куярга мөмкин булган. Шул рәвешле, китапны кадерләп саклаганнар, чөнки бу кульязма китаплар чыннан да бик кыйммәтле булган». («Научный Татарстан» журналы, 2009 № 2)

Рус дәүләтендә кәгазьдән XIV йөздә файдалана башлаганнар. Аны Европадан сатып алганнар. Галимнәр фикеренчә, «бумага» сүзе төрки pamuk (мамык) сүзеннән алынган булса кирәк.

Россиядә кәгазь җитештерү эше XVIII гасырда җайга салынган. Чимал буларак нигездә иске тукыма кулланылган: флоттан иске кораб җилкәннәре, аркан һәм баулар җыелган, крестьяннар «чүпрәк салымы» түләргә тиеш булган.

Мөселманнар уйлап тапкан кәгазь җитештерү ысулының бик озак кулланылуын мәгърифәтчебез Г. Бубиның «Кыйраәте төрки» китабыннан да күрәбез. 1899 елда чыккан бу китабында ул болай дип яза: «Китапларыгыздагы вә яза торган кәгазьләрне ни-нәрсәдән ясыйлар, беләсезме? Иске чүпрәкләрдән, саламнан, төрле-төрле кипкән үләннәрдән, пычкы чүпләреннән ясаладыр. Әмма бездәге кәгазьләрнең күбрәге иске киндер чүпрәктән ясалгандыр. Кәгазь ясаучылар иң элек бу чүпрәкләрне бик зур казанга салып, камыр булганчы кайнатырлар. Аннан соң бик нык тазартып вә дарулап агартырлар. Соңыннан уклау кебек нәрсә белән бик юка итеп җәярләр. Соңыннан киптереп, базарга чыгарып сатарлар».

XIX гасырның икенче яртысында дөньяда кәгазьне агач чималдан җитештерә башлыйлар.



Фотоның авторы: Joanna Kosinska/unsplash.com

**Сәхифәне Рәмзилә Маннанова әзерләде**

# Тәлбинә — хәдистә искә алынган ботка


Фотоның авторы: Alexandru Acea / unsplash.com

**Тәлбинә – сөттә пешерелә торган арпа боткасы, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисендә искә алынган. Ботканың атамасы гарәп «ләбән» (сөт) сүзеннән барлыкка килгән.**

### АРПАНЫҢ ФАЙДАСЫ

Бу файдалы ботка турында хәдистә болай диелгән: «Тәлбинә авыру кешенең калебен тынычландыра һәм кайгы-хәсрәтне бераз җиңеләйтә» (әл-Бохари). Ягъни бу ризык кайгы кичерүче кешегә тынычланырга ярдәм итә ала икән. Шулай ук Гайшә анабыз радыяллаһу ганһәнең берәр туганы үлсә, аның хатын-кызларга тәлбинә пешереп, якын туганнарын сыйларга киңәш итүе билгеле. Бу аларны бераз юатыр өчен эшләнгән.

Арпаны кешеләр борынгы чордан ук үстереп, онын – көлчә һәм ипиләр, ә ярмасын боткалар пешерү, ашка өстәү өчен, йорт хайваннарына ашатыр өчен дә файдаланган. Кызганыч, бүгенге көндә аш-суда арпа сирәк кулланыла.

Ә арпаның файдасы бик зур. Табиблар, диетологлар әйтүенчә, арпадан пешерелгән ризыклар А, Е, PP витаминнарына һәм бигрәк тә В витаминнарына бай. Анда калий, магний, кальций, күкерт һәм бакыр кебек минераллар бар. Һәм боларның барысы да кешенең нерв системасына уңай тәэсир итә икән.

В витаминнары кешегә игътибарын тупларга, кәефен күтәрергә, ачуланган вакытта тынычланырга һәм баш миенә яхшырак эшләргә ярдәм итә. Магний, мәсәлән, нерв системасының дөрес эшләвенә тәэсир итә, киеренкелекне бетерә. Моннан тыш, арпа клетчаткага бай, ул ашказаны-эчәк трактын чистарта. Арпага аллергия яки целиакия (организмның глютенны кабул итмәве) авыруы белән авыручы кешеләрдән кала, табиблар арпаны башка бар кешегә дә файдалы дип саный.

Гомумән, арпаның аерым ир-атлар, хатын-кызлар, ашказаны-эчәк авыруларыннан интегүчеләр өчен файдасы турында мәгълүмат шактый. Бүген кибетләрдә арпаның онын да, ярмасын да һәм хәтта «каһвәсен» дә табарга мөмкин.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнарга арпаның файдасы турында күптән хәбәр иткән булган. Күп кенә хәдисләрдә аның һәм сәхабәләрнең арпа оныннан пешерелгән көлчәләр ашавы хәбәр ителә. Һәм бүген без, күңел тынычлыгы һәм тән сихәте алу максаты белән дә, Расүлебез галәйһиссәламнең Сөннәтенә иярү нияте белән дә, арпадан тәлбинә кебек ризыкны пешереп карый алабыз.

### ТӘЛБИНӘНЕ НИЧЕК ПЕШЕРЕРГӘ?

Бүгенге көнгә кадәр тәлбинәнең мондый рецепты сакланып килгән:

– 2 аш кашыгы эре бөртекле яки бик вак итеп тарттырылган арпа оны;
– 1 стакан сөт яки су (яки бер өлеш сөт һәм бер өлеш су);
– 1–2 чәй калагы бал;
– киптерелгән җиләк-җимешләр, чикләвекләр.

Салкын сөт яки суга арпа онын салып, яхшылап болгатырга. Талгын утта ботка куерганчыга кадәр пешерергә (кайнап чыкканнан соң 10–15 минут вакыт кирәк булырга мөмкин).

Тәм өчен боткага бераз дарчин (корица) яки кардамон өстәргә мөмкин. Ботка әзер булгач, бал өстәргә. Теләк буенча пешкән тәлбинәгә җимешләр, чикләвекләр өстәргә мөмкин.

# Пәйгамбәребез галәйһиссәлам кабак яраткан

**Хәзрәти Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе мондый хәдис тапшырган: «Бер тегүче Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне үзе пешергән ризык белән сыйларга чакырды. Мин аның белән бардым. Тегүче безгә арпа оныннан ипи һәм шулпа китерде. Шулпада кабак кисәкләре белән киптерелгән ит бар иде. Мин Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең шулпадан кабак кисәкләрен эзләп алганын күрдем. Шул көннән мин кабакны ярата башладым (әл-Бохари). Шулай ук Әнәс радыяллаһу ганһе: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм кабак ярата иде», – дип әйткән.**

Башка мәшһүр сәхабә Җәбир радыяллаһу ганһе болай дигән: «Бер заман мин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең йортына кергәч, кабак ятканын күрдем. «Бу нәрсә?» – дип сорадым. Ул: «Бу – кабак. Аның белән без ризыгыбызның күләмен арттырабыз», – дип җавап бирде» (Ибне Мәҗә).

Бүгенге көндә бу файдалы яшелчә аш-суда да, медицинада да, косметологиядә дә киң кулланыла. Халкыбыз яратып кабактан тәмле ризыкларын әзерли. К. Насыйри 1894 елда дөнья күргән «Пешекчегә аш-су әзерләү турында юллама» хезмәтендә кабактан мондый ризыклар тәкъдим итә:

### КАБАК КӘБАБЫ

Яхшы бер кабак ал. Кисәкләп тура, әмма бик вак булмасын. Азрак тозла, аннан соң һәрбер кисәкне онга салып әвәлә. Табага куй, җитәрлек май сал, мичкә куеп пешер. Кабак пешкәч, өч йомырканы сытып, бик яхшы тугла. Ярты стакан каймак сал. Боларны барын бергә кабак өстенә сип, аннан соң янә мичкә куй. Ярты сәгать торсын. Ашар вакытта алып дәстәрханыңа куй.

### КАБАК БОТКАСЫ

Яхшы өлгергән кабакны тура, эчен ал, кабыгын арчы. Бер бакыр савытка сал, өстенә су сал, мичкә куеп кайнат, казанда да ярый. Тәмам пешеп йомшагач, бер иләккә бушат. Су саркып беткәч кашык белән из, өстенә кайнаган сөт сал, кирәк кадәрчә тары сал, өч кашык май сал, янә мичкә куй. Тәмам дымланып пешсен. Тәгам булыр.

**Сәхифәне Рәмзилә Маннанова әзерләде**

# Дәвалануның төп юллары


Фотоның авторы: Heather Barnes/unsplash.com

**Әллә заманасы шундый – күп кеше авырый бүген. Салкын тию, ОРВИ кебек гадәти («көндәлек») сырхаулардан адәм баласының әллә ни исе китмәсә, кайбер җитди авырулар вакытында күпләрнең күңеле төшә, ә дәвалану нәтиҗә бирмәсә, кеше паникага бирелеп, ничектер хафаланып, гаҗизләнеп кала.**

Ислам динендә авыруларны дәвалау буенча анык киңәшләр бирелә. Әйтик, каты авырып киткәнсең икән, һичшиксез табибларга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә «Табиб булмаган җирдә яшәмәгез» дип әйтелүе дә юкка түгелдер.

Бу темага багышланган икенче бер хәдистә тагын болай диелә: «Аллаһы Тәгалә барлык авыруларны бар кылган һәм алар белән бергә дәваларын да бар иткән. Фәкать картлыктан гына дәва юк». Димәк, мөэмин-мөселманнар, нинди чир белән авырый башлауга карамастан, аның дәвасы барлыгына ихлас инанып, дәвалану юлларын эзләргә тиешләр. Әмма шунысын да истә тоту мөһим: табиблар билгеләгән дарулардан, ягъни бәдәни ысуллардан, тыш, мөселманнарга дәвалануның рухи ысулларын куллану да мәслихәт.

Шифа эзләүнең гомум этапларына килгәндә исә, аларны болай тәгаенләп булыр иде:

1. Авыру турында белгәч, шифасын бирүне сорап, ихлас шундый дога кылырга: «Әлхәмду лилләһи Раббиль гааләмиин әссаләәтү вәссәләәму галәә расүлиһи Мухәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйин. Йә Раббым! Үз хикмәтең һәм рәхмәтең белән шушы авыруны миңа бирдең… Һәрбер авыру һәм аның дәвасы – фәкать Синнән генә. Хәерле шифаларын да биреп, миңа сихәтләнергә, терелергә насыйп ит!»

Бу дога ике рәкәгать хаҗәт намазы укыганнан соң кылынса, тагын да яхшырак.

2. Динебездә киңәш ителгәнчә, мөмкин кадәр тизрәк табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Табибка керер алдыннан өч мәртәбә «Аятелкөрси»не уку хәерле.

3. Табиб язган даруларны кулланыр алдыннан «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим» дип әйтергә. Күңелдән даруларга түгел, ә Аллаһыга тәвәккәлләргә, Аның рәхмәтенә һәм ярдәменә ихлас өмет итәргә.

4. Кайбер очракларда авыру кылган гөнаһлар өчен җәза буларак бирелергә мөмкин. Ислам динендә тәүбә, ягъни гөнаһ-хаталарга үкенеп, Аллаһыдан ярлыкау сорау, дәвалану процессында да бик әһәмиятле. Шуңа күрә авырый башлаган кешегә: «Йә Раббым! Белеп һәм белми кылган гөнаһларымны, бәндәчелек белән кылган хата-кимчелекләремне гафу итсәң иде», – дип дога кылырга, гомумән, мөмкин кадәр ешрак «әстәгъфируллаһ» («Аллаһыдан гафу үтенәм») дип кабатларга кирәк. Аллаһы Тәгалә Үзеннән гафу сораучы инсаннарны якын итә, аларның гозер-үтенечләрен үти, ярдәменнән ташламый.

5. Медицина күрсәтмәләреннән тыш, мөселманнарга өшкерү ысулларын да файдалану киңәш ителә. Аның өчен хәзрәт-абыстайларга мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Ышанычлы чыганаклардан билгеле булганча, иң зур сәламәтләндерү көченә «Фатиха» сүрәсе ия.

Хәдисләрнең берсендә «Фатиха» сүрәсендә барлык авырулардан дәва бар» дип хәбәр ителә (Әл-Бәйһакый, «Шүгаб әл-иман» 2/450, «Әд-Дүрруль-мансур», 1/16). Башка бер хәдистә «Фатиха» сүрәсендә үлемнән кала барлык авырулардан шифа бар» дип төгәллек кертелә.

Гадәттә «Фатиха» сүрәсен авырып яткан кеше өстеннән укыйлар. Шулай ук авырган җиргә кулны куеп, «Фатиха»ны 7 мәртәбә укырга яисә бу сүрәне 7 мәртәбә суга укып, шул суны эчәргә мөмкин.

6. Ислам динендә дәвалануның халык ысулларын куллану да тыелмый. Шулай ук бал һәм кара тмин маен файдалану киңәш ителә.

7. Мөселман галимнәре белдергәнчә, дәвалануның иң нәтиҗәле ысулларыннан берсе – ул садака бирү. Әбү Бәкер әл-Хәбб Газиз (Аллаһ аннан разый булсын) үз тормышында булган шундый хәлне сөйләгән: «Бервакыт мин куркыныч авыру белән авырый башладым. Моны минем тәкъва күршем белгәч, болай диде: «Пәйгамбәребезнең «Авыруларыгызны садака ярдәмендә дәвалагыз» дигән нәсыйхәтен куллан!»

Бу җәй чоры иде. Мин күп итеп карбызлар сатып алдым да, әйләнә-тирәдәге фәкыйрьләрне һәм бала-чаганы чакырып, шул карбызларны аларга ашаттым. Соңыннан алар кулларын күтәреп, минем савыгуымны теләп дога кылдылар. Аллаһ белән ант итәм, икенче көнне иртән мин Аллаһы Тәгаләнең олуг рәхмәте белән сау-сәламәт һәм имин хәлдә уянып тордым».

**Ришат хәзрәт Курамшин,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

## ДҮШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55,18:00** «Мин нигә яулык бәйләмим?» 12+
**08:05,18:10** «Фикер» 16+
**08:55** «Иң гүзәл исемнәр» 12+
**09:05,19:00,22:35,12:50** «Мәслихәт» 12+
**09:30,19:25,14:05,22:00** «Зәкят» 12+
**09:40,19:35** «Гаҗәеп дөнья серләре. Бөҗәкләр дөньясы» 12+
**09:50** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:00,19:45** «Имамнан сорыйк» 12+
**10:50,20:35** Мульфильм 6+
**11:05** «Хәдис дәресләре» 12+
**11:35** «Минбар» 12+
**12:00** Азан
**12:05,21:00** «Учимся читать намаз» 12+
**12:25,21:45** «Адабы Ислама» 12+
**12:40,21:35** «Чудеса сотворений. Мир растений» 12+
**13:15,00:40** «Узнаем у имама» 12+
**14:15** «Уроки семьи» 12+
**14:40,21:20** Мультфиль 6+
**14:55,00:05** Док. фильм 12+
**15:30,23:00** «Давай поговорим» 12+
**16:20,22:25** «Почему я не надеваю платок» 12+
**16:30** «Аль-Истикама» 12+
**16:55,23:50** «Спросите у знающих» 12+
**17:10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**17:25,01:45** «И читай Коран размеренно» 12+
**17:45,01:30** «В тени милости Аллаха» 12+
**20:50** Җан авазы
**22:10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**02:05** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## СИШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55,20:45** «Тәмле булсын» 12+
**08:15,18:00** «Фикер» 16+
**09:00,18:45** «Әкиятләр иле» 6+
**09:10,18:55** «Абыстай сүзе» 12+
**09:55** «Коръән могҗизалары» 12+
**10:05,19:55** «Имамнан сорыйк» 12+
**10:55,19:40** Мульфильм 6+
**11:10,12:55,23:30** «Мәслихәт» 12+
**11:35** «Минбар» 12+
**12:00** Азан
**12:05** «Учимся читать намаз» 12+
**12:25,21:25** «Финансовые взаимоотношения в Исламе» 12+
**12:45,21:45** «Чудеса сотворений. Мир растений» 12+
**13:20,22:05** «Узнаем у имама» 12+
**14:10,21:55** «Каждый может стать Коран-хафизом» 12+
**14:20,21:05** Мультфиль 6+
**14:35,22:55** Док. фильм 12+
**15:10,00:05** «Спросите у знающих» 12+
**15:35,00:40** «Голос разума» 12+
**16:10** «Совершенные женщины» 12+
**16:25,00:20** «Вера в предопределение» 12+
**16:35** «В тени милости Аллаха» 12+
**16:50,23:55** «Золотой век исламкой цивилизации» 12+
**17:00,01:15** «Счастье без границ» 12+
**17:10,01:25** «История ислама в России» 12+
**17:30,00:30** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**17:40,01:45** «Так поступал Пророк» 12+
**17:55,21:20** «Энциклопедия для юных мусульман» 6+
**02:00** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ЧӘРШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55,18:00** «Мин нигә яулык бәйләмим?» 12+
**08:05,18:10** «Фикер» 16+
**08:55** «Иң гүзәл исемнәр» 12+
**09:05,19:00,22:35,12:50** «Мәслихәт» 12+
**09:30,19:25,14:05,22:00** «Зәкят» 12+
**09:40,19:35** «Гаҗәеп дөнья серләре. Бөҗәкләр дөньясы» 12+
**09:50** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:00,19:45** «Имамнан сорыйк» 12+
**10:50,20:35** Мульфильм 6+
**11:05** «Хәдис дәресләре» 12+
**11:35** «Минбар» 12+
**12:00** Азан
**12:05,21:00** «Учимся читать намаз» 12+
**12:25,21:45** «Адабы Ислама» 12+
**12:40,21:35** «Чудеса сотворений. Мир растений» 12+
**13:15,00:40** «Узнаем у имама» 12+
**14:15** «Уроки семьи» 12+
**14:40,21:20** Мультфиль 6+
**14:55,00:05** Док. фильм 12+
**15:30,23:00** «Давай поговорим» 12+
**16:20,22:25** «Почему я не надеваю платок» 12+
**16:30** «Аль-Истикама» 12+
**16:55,23:50** «Спросите у знающих» 12+
**17:10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**17:25,01:45** «И читай Коран размеренно» 12+
**17:45,01:30** «В тени милости Аллаха» 12+
**20:50** Җан авазы
**22:10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**02:05** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ПӘНҖЕШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55,20:45** «Тәмле булсын» 12+
**08:15,18:00** «Фикер» 16+
**09:00,18:45** «Әкиятләр иле» 6+
**09:10,18:55** «Абыстай сүзе» 12+
**09:55** «Коръән могҗизалары» 12+
**10:05,19:55** «Имамнан сорыйк» 12+
**10:55,19:40** Мульфильм 6+
**11:10,12:55,23:30** «Мәслихәт» 12+
**11:35** «Минбар» 12+
**12:00** Азан
**12:05** «Учимся читать намаз» 12+
**12:25,21:25** «Финансовые взаимоотношения в Исламе» 12+
**12:45,21:45** «Чудеса сотворений. Мир растений» 12+
**13:20,22:05** «Узнаем у имама» 12+
**14:10,21:55** «Каждый может стать Коран-хафизом» 12+
**14:20,21:05** Мультфиль 6+
**14:35,22:55** Док. фильм 12+
**15:10,00:05** «Спросите у знающих» 12+
**15:35,00:40** «Голос разума» 12+
**16:10** «Совершенные женщины» 12+
**16:25,00:20** «Вера в предопределение» 12+
**16:35** «В тени милости Аллаха» 12+
**16:50,23:55** «Золотой век исламкой цивилизации» 12+
**17:00,01:15** «Счастье без границ» 12+
**17:10,01:25** «История ислама в России» 12+
**17:30,00:30** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**17:40,01:45** «Так поступал Пророк» 12+
**17:55,21:20** «Энциклопедия для юных мусульман» 6+
**02:00** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ҖОМГА

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55,18:00** «Мин нигә яулык бәйләмим?» 12+
**08:05,18:10** «Фикер» 16+
**08:55** «Иң гүзәл исемнәр» 12+
**09:05,12:50,19:00,22:35** «Мәслихәт» 12+
**09:30,14:05,19:25,22:00** «Зәкят» 12+
**09:40,19:35** «Гаҗәеп дөнья серләре. Бөҗәкләр дөньясы» 12+
**09:50** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:00** «Имамнан сорыйк» 12+
**10:50,14:40,20:35,21:20** Мульфильм 6+
**11:05** «Хәдис дәресләре» 12+
**11:35** «Минбар» 12+
**12:00** Азан
**12:05,21:00** «Учимся читать намаз» 12+
**12:25,21:45** «Адабы Ислама» 12+
**12:40,21:35** «Чудеса сотворений. Мир растений» 12+
**13:15** «Узнаем у имама» 12+
**14:15** «Уроки семьи» 12+
**14:55,00:05** Док. фильм 12+
**15:30,23:00** «Давай поговорим» 12+
**16:20,22:25** «Почему я не надеваю платок» 12+
**16:30** «Аль-Истикама» 12+
**16:55** «Спросите у знающих» 12+
**17:10,22:10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**17:25** «И читай Коран размеренно» 12+
**17:45** «В тени милости Аллаха» 12+
**19:45** «Имамнан сорыйк» 12+
**20:50** Җан авазы
**23:50** «Спросите у знающих» 12+
**00:40** «Узнаем у имама» 12+
**01:30** «В тени милости Аллаха» 12+
**01:45** «И читай Коран размеренно» 12+
**02:05** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ШИМБӘ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55,20:45** «Тәмле булсын» 12+
**08:15** «Фикер» 16+
**09:00,18:45** «Әкиятләр иле» 6+
**09:10,18:55** «Абыстай сүзе» 12+
**09:55** «Коръән могҗизалары» 12+
**10:05,19:55** «Фарук» 12+
**10:55,19:40,21:05,14:20** Мульфильм 6+
**11:10** «Мәслихәт» 12+
**11:35** «Минбар» 12+
**12:00** Азан
**12:05** «Учимся читать намаз» 12+
**12:25,21:25** «Финансовые взаимоотношения в Исламе» 12+
**12:45,21:45** «Чудеса сотворений. Мир растений» 12+
**12:55,23:30** «Уроки тафсира» 12+
**13:20,22:05** «Узнаем у имама» 12+
**14:10,21:55** «Каждый может стать Коран-хафизом» 12+
**14:35,22:55** Док. фильм 12+
**15:10,00:05** «Спросите у знающих» 12+
**15:35,00:40** «Голос разума» 12+
**16:10** «Совершенные женщины» 12+
**16:25,00:20** «Вера в предопределение» 12+
**16:35** «В тени милости Аллаха» 12+
**16:50,23:55** «Золотой век исламкой цивилизации» 12+
**17:00,01:15** «Счастье без границ» 12+
**17:10,01:25** «История ислама в России» 12+
**17:30,00:30** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**17:40,01:45** «Так поступал Пророк» 12+
**17:55,21:20** «Энциклопедия для юных мусульман» 6+
**18:00** «Фикер» 16+
**02:00** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ЯКШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55,18:05** «Мин нигә яулык бәйләмим?» 12+
**08:05,18:15** «Фикер» 16+
**08:55** «Иң гүзәл исемнәр» 12+
**09:05,12:50,19:05,22:40** «Мәслихәт» 12+
**09:30,19:30,22:05** «Зәкят» 12+
**09:40,19:40** «Гаҗәеп дөнья серләре. Бөҗәкләр дөньясы» 12+
**09:50** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:00,19:50** «Имамнан сорыйк» 12+
**10:50,14:40,20:40,21:25** Мульфильм 6+
**11:05** «Хәдис дәресләре» 12+
**11:35** «Минбар» 12+
**12:00** Азан
**12:05,21:05** «Учимся читать намаз» 12+
**12:25,21:50** «Адабы Ислама» 12+
**12:40,21:40** «Чудеса сотворений. Мир растений» 12+
**13:15** «Узнаем у имама» 12+
**14:05** «Закят» 12+
**14:15** «Уроки семьи» 12+
**14:55,00:10** Док. фильм 12+
**15:30,23:05** «Давай поговорим» 12+
**16:20,22:30** «Почему я не надеваю платок» 12+
**16:30,00:45** «Фарук» 12+
**17:20,23:55** «Спросите у знающих» 12+
**17:35,22:15** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**17:45,01:50** «И читай Коран размеренно» 12+
**20:55** «Җан авазы» 12+
**01:35** «В тени милости Аллаха» 12+
**02:10** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+


# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**СӘМИГУЛЛИН К. И.**

«Хозур» нәшрият йорты директоры
**ХӘМИДУЛЛИН Р. Ә.**

ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**МӨБАРӘКОВ Б. Р.**

Татарстанның баш казые
**ФАЗЛЫЕВ Җ. В.**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**ӘДҺӘМОВ Г. К.**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Ситдикова Г. Р., Маннанова Р. Р.**
Логотип авторы: **Димасов Э. И.** Биткә салучы: **Гарифуллин И. Ф.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:** 420111, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 йорт
**Электрон адресы:** izdat@huzur.ru
**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38 йорт).
**НӘШИР:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 йорт).
Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 26 нчы маенда ПИ № ТУ16 - 01750 номеры белән теркәлде.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 000 данә. Заказ № 2702.
График буенча – 23.12.2024, 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.
Газетага ярты елга язылу бәясе – 188,94 сум.
Индексы – П4333. Чыгу көне: 25.12.2024.
Казан шәһәренең мәчетләрендә 26 нчы декабрь көнне таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## ГЫЙНВАРЬ 2025 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | | Кояш чыга | ЗӘВӘЛ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ, ИФТАР | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01 | Чәрш | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 11:47 | 12:00 | 13:34 | 15:21 | 17:18 |
| 02 | Пәнҗ | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 11:47 | 12:00 | 13:35 | 15:22 | 17:20 |
| 03 | Җом | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 11:48 | 12:00 | 13:36 | 15:23 | 17:21 |
| 04 | Шим | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 11:48 | 12:00 | 13:37 | 15:25 | 17:22 |
| 05 | Якш | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 11:48 | 12:00 | 13:39 | 15:26 | 17:23 |
| 06 | Дүш | 05:52 | 06:40 | 08:10 | 11:49 | 12:00 | 13:40 | 15:28 | 17:24 |
| 07 | Сиш | 05:52 | 06:40 | 08:10 | 11:49 | 12:00 | 13:41 | 15:29 | 17:25 |
| 08 | Чәрш | 05:51 | 06:39 | 08:09 | 11:50 | 12:00 | 13:43 | 15:31 | 17:26 |
| 09 | Пәнҗ | 05:51 | 06:38 | 08:08 | 11:50 | 12:00 | 13:44 | 15:32 | 17:28 |
| 10 | Җом | 05:50 | 06:38 | 08:08 | 11:51 | 12:00 | 13:46 | 15:34 | 17:29 |
| 11 | Шим | 05:50 | 06:37 | 08:07 | 11:51 | 12:00 | 13:47 | 15:36 | 17:30 |
| 12 | Якш | 05:49 | 06:36 | 08:06 | 11:51 | 12:00 | 13:49 | 15:37 | 17:32 |
| 13 | Дүш | 05:49 | 06:35 | 08:05 | 11:52 | 12:00 | 13:50 | 15:39 | 17:33 |
| 14 | Сиш | 05:48 | 06:34 | 08:04 | 11:52 | 12:00 | 13:52 | 15:41 | 17:35 |
| 15 | Чәрш | 05:47 | 06:33 | 08:03 | 11:52 | 12:00 | 13:54 | 15:43 | 17:36 |
| 16 | Пәнҗ | 05:47 | 06:31 | 08:01 | 11:53 | 12:00 | 13:55 | 15:45 | 17:38 |
| 17 | Җом | 05:46 | 06:30 | 08:00 | 11:53 | 12:00 | 13:57 | 15:46 | 17:39 |
| 18 | Шим | 05:45 | 06:29 | 07:59 | 11:53 | 12:00 | 13:59 | 15:48 | 17:41 |
| 19 | Якш | 05:44 | 06:28 | 07:58 | 11:54 | 12:00 | 14:01 | 15:50 | 17:42 |
| 20 | Дүш | 05:43 | 06:26 | 07:56 | 11:54 | 12:00 | 14:03 | 15:52 | 17:44 |
| 21 | Сиш | 05:42 | 06:25 | 07:55 | 11:54 | 12:00 | 14:04 | 15:54 | 17:45 |
| 22 | Чәрш | 05:41 | 06:23 | 07:53 | 11:55 | 12:00 | 14:06 | 15:56 | 17:47 |
| 23 | Пәнҗ | 05:40 | 06:22 | 07:52 | 11:55 | 12:00 | 14:08 | 15:58 | 17:49 |
| 24 | Җом | 05:39 | 06:20 | 07:50 | 11:55 | 12:00 | 14:10 | 16:00 | 17:50 |
| 25 | Шим | 05:38 | 06:19 | 07:49 | 11:55 | 12:00 | 14:12 | 16:02 | 17:52 |
| 26 | Якш | 05:36 | 06:17 | 07:47 | 11:56 | 12:00 | 14:14 | 16:05 | 17:54 |
| 27 | Дүш | 05:35 | 06:16 | 07:46 | 11:56 | 12:00 | 14:16 | 16:07 | 17:56 |
| 28 | Сиш | 05:34 | 06:14 | 07:44 | 11:56 | 12:00 | 14:18 | 16:09 | 17:57 |
| 29 | Чәрш | 05:33 | 06:12 | 07:42 | 11:56 | 12:00 | 14:20 | 16:11 | 17:59 |
| 30 | Пәнҗ | 05:31 | 06:10 | 07:40 | 11:56 | 12:00 | 14:22 | 16:13 | 18:01 |
| 31 | Җом | 05:30 | 06:08 | 07:38 | 11:56 | 12:00 | 14:24 | 16:15 | 18:03 |